ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2019 елның 18 ноябре), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^1$ – $10^3$ пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$10^1$) төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән стандарт торакка кертеп карау шартларына туры килә торган торак урыннарны (алга таба – стандарт торак) сатып алу хокукына ия гражданнар категорияләре исемлеген раслау;

$10^2$) мөрәҗәгать итүче гражданнарның стандарт торак сатып алу хокукына ия гражданнарның билгеләнгән категорияләренә туры килүен җирле үзидарә органнары тарафыннан тикшерү тәртибен, стандарт торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан төзү һәм раслау тәртибен, аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

$10^3$) стандарт торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертелгән гражданнарның Татарстан Республикасы буенча җыелма реестрын алып бару тәртибен һәм күрсәтелгән реестрда булган белешмәләрне Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә стандарт торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яисә стандарт торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирү тәртибен билгеләү;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 27 декабрь
№ 117-ТРЗ